**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **с. Тюлячи** **БОЕРЫК**

« 29 » декабрь 2018 № 374

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 288 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия каршында мәгълүмати-пропаганда төркеме эшчәнлеге турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнарының «Террорчылыкка каршы тору турында» 2016 елның 6 июлендәге 35-ФЗ номерлы Федераль законның 5.2 статьясында каралган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру һәм террорчылык һәм экстремизм идеологиясенә каршы көрәшкә, халыкның хокукый һәм дини белемен күтәрүгә юнәлдерелгән чараларны үтәү максатларында,

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 288 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия каршында мәгълүмати-пропаганда төркеме эшчәнлеге турында» боерыгына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

1.1. «2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия каршындагы мәгълүмати-пропаганда төркеме составын яңа редакциядә 2 номерлы кушымта нигезендә расларга;

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 288 номерлы боерыгына 2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия каршында мәгълүмати-пропаганда төркеме составы

Эшче төркем җитәкчесе:

| | | |
|---|---|---|
| Нурмөхәммәтов А.Ә. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |

Эшче төркем җитәкчесе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Иксанов Д. С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы. |

Эшче төркем секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Имамиева Ф. М. | - | «Теләче туган якны өйрәнү музее» МБМУ директоры. |

Эшче төркем әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Ибраһимов З. З. | - | «Олимп» МБУ директоры; |
| Дәүлиева Р. М. | - | МБУ «Теләче муниципаль районы җирлекара китапханәсе» директоры; |
| Шакирова Г.Р. | - | МКУ «Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» җитәкчесенең тәрбия эшләре буенча урынбасары; |
| Хуҗин Л. Й. | - | «Татмедиа» АҖ филиалы «Теләчеинформ» МҮ директоры (килешү буенча); |
| Шәфигуллина Г.Н. | - | «Родник» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» ДАУСО директоры урынбасары (килешү буенча); |
| Сәйфетдинов Р.Р. | - | «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» МБУ директоры. |

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия каршындагы мәгълүмати-пропаганда төркеменең эш планын кушымта нигезендә 2019 елда расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ә. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕГЕ

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «29» декабрь 2018 № 374 боерыгына кушымта

2019 елда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия каршында мәгълүмат-пропаганда төркеменең эш планы

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Муниципаль китапханәләрдә китап күргәзмәләре оештыру, мәгариф оешмаларында мәгълүмат стендлары булдыру, толерантлык тәрбияләүгә, экстремизмны профилактикалауга, террорчылык идеологиясенә каршы көрәшкә юнәлдерелгән плакатлар рәсмиләштерү | ел дәвамында | Җаваплылар: Дәүлиева Р.М., Шакирова Г.Р. |
| 2. | Халыкның төрле категорияләре белән семинарлар, лекцияләр, әңгәмәләр, күргәзмәләр, экспозицияләр һәм башка эш формалары булган экстремизмга һәм террорчылыкка каршы көрәш чараларын үткәрү | квартал саен | Җаваплы: Иксанов Д. С. |
| 3. | Террорчылыкны, экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар җитәкчеләре һәм вәкилләре белән очрашулар һәм профилактик әңгәмәләр үткәрү | ярты елга бер тапкыр | Җаваплы: Нурмөхәммәтов А.А., Сәйфетдинов Р.Р., АҖ башлыклары (килешү буенча) |
| 4. | Террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау, экстремистлык күренешләрен булдырмау һәм милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукларны гамәлгә ашыру эшендә учреждение һәм оешмалар җитәкчеләренә, авыл җирлекләре башлыкларына методик ярдәм күрсәтү | мөрәҗәгать иткәндә, проблемалы мәсьәләләрне ачыклаганда | Җаваплы: Ибраһимов З.З., Дәүлиева Р. М. |
| 5. | Экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау материаллары, мәгълүмати-пропаганда төркеме эшчәнлеге, Теләче муниципаль районы сайтында, «Теләче» - «Тюлячи» газетасында экстремизм һәм террорчылыкны | ел дәвамында айга кимендә бер тапкыр | Җаваплы: Хуҗин Л. Й. (килешү буенча), Сәйфетдинов Р.Р. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | профилактикалау чараларын яктырту | | |
| 6. | Басма массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет челтәре даими мониторингын гамәлгә ашыру, раса, этник һәм дини дошманлык һәм нәфрәт уяту омтылышларын ачыклау предметына | даими | Җаваплылар:<br>Имамиева Ф. М.,<br>Шәфигуллина Г.Н.<br>(килешү буенча) |
| 7. | Укучыларны патриотик тәрбияләү буенча үткәрелә торган чараларда мәгълүмати ярдәм | ай саен | Җаваплы:<br>Шакирова Г.Р. |
| 8. | Үзен дини формаль булмаган берләшмәләргә кертүче муниципаль район территориясендә яшәүче затлар белән профилактик чаралар үткәрү | кирәк булган очракта | Җаваплы:<br>Нурмөхәммәтов А.А.,<br>Ибраһимов З.З.,<br>АҖ башлыклары<br>(килешү буенча),<br>Сәйфетдинов Р.Р. |
| 9. | Мәгариф учреждениеләрендә криминаль хәлләр барлыкка килгәндә һәм массакүләм чаралар уздырганда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре буенча профилактик эш оештыру (очрашулар, әңгәмәләр, ата-аналар җыелышлары һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләре катнашында класс сәгатьләре) | квартал саен | Җаваплылар:<br>Иксанов Д.С.,<br>Шакирова Г.Р.,<br>Сәйфетдинов Р.Р. |
| 10. | ТИН курсы укытучысы, педагог-оештыручылар, мәгариф оешмалары җитәкчеләренең тәрбия эше буенча урынбасарлары, спорт төрләренең өстәмә белем бирү педагоглары белән мәктәп тирәлегендә экстремизмны профилактикалау эшен оештыру мәсьәләләре буенча очрашулар | ел дәвамында | Җаваплылар:<br>Шакирова Г.Р.,<br>Сәйфетдинов Р.Р.,<br>Ибраһимов З. З. |
| 11. | Рәсми рәвештә теркәлгән иҗтимагый һәм дини оешмаларга мәдәни-агарту программаларын, социаль юнәлешле эшчәнлекне гамәлгә ашыруда, милләтара һәм конфессияара диалогны һәм хезмәттәшлекне үстерүгә юнәлдерелгән уртак чараларны әзерләүдә һәм уздыруда ярдәм күрсәтү | ел дәвамында | Җаваплылар:<br>Нурмөхәммәтов А.А.,<br>Ибраһимов З.З.,<br>Иксанов Д. С. |